КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 16 июнь г.Казань № 720

Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә М.Н.Садыйков исемен бирү турында

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры, Татарстан Республикасының атказанган табибы Садыйков Марат Наил улы истәлеген мәңгеләштерү максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә М.Н.Садыйков исемен бирү һәм аны алга таба «М.Н.Садыйков исемендәге 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе дип атау турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына 60 көн эчендә Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе Уставына тиешле үзгәрешләр кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин